СОВЕТ САЛАУССКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ САЛАВЫЧ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**«23» март 2026 ел**

**КАРАР**
**№23**

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлегенең генераль планын әзерләү зарурлыгы булмау турында**

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының кайбер авыл җирлекләре территориясендә әлеге җирлек территорияләреннән файдалануны үзгәртү күздә тотылмавына һәм социаль-икътисадый үсеш стратегияләренең шулай ук Россия Федерациясен территориаль планлаштыру документлары, Россия Федерациясе субъектын территориаль планлаштыру документлары, Балтач муниципаль районының территориаль планлаштыру документлары белән раслануына бәйле рәвештә федераль һәм региональ әһәмияттәге объектларны, муниципаль районның җирле әһәмияттәге объектларын әлеге җирлекләр территориясендә урнаштыру каралмавына бәйле рәвештә һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Салавыч авыл җирлеге Советы карар кылды:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Салавыч авыл җирлегендә 2026 елның «31» декабренә кадәр генераль планны эшләү зарурлыгы булмавын танырга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Салавыч авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Законы нигезендә 1 пунктта күрсәтелгән авыл җирлекләрендә җирдән файдалану кагыйдәләре һәм төзелеш проектын әзерләү турында карар кабул итү тәкъдиме белән Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына мөрәҗәгать итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль

районының рәсми сайтында (baltasi. tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Салавыч авыл җирлеге башлыгы Р.К.Латипов